| | |
|---|---|
| ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

3 октябрь 2019 ел с. Ульянково №2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Корноухово торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Корноухово авылы, Бутанина урамы, 57 нче йорт адресы буенча урнашкан Корноухово авыл клубында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Корноухово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2019 елның 14 октябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Корноухово авылы, Бутанина урамы, 57 нче йорт адресы буенча урнашкан Корноухово авыл клубында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Корноухово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2019 елның 17 октябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Корноухово авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бер мең йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

а) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту»

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**